Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Яңа Чыршылы авыл җирлегенең
Яңа Чыршылы торак пункты гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 18 ноябре

№ 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Яңа Чыршылы торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 18 ноябрендә узган «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Яңа Чыршылы авыл җирлеге Яңа Чыршылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

Җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү,

Яңа чыршылы бистәсе территориясендә үлән чабу,

Үзәк урамындагы иске агачларны кисү;

торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Яңа Чыршылы торак пунктында Лесная урамы буенча туфрак- вак таш җәелгән юлларны ремонтлау,

-Яңа Чыршылы торак пунктында чокыр ремонтлау (асфальт)

- Яңа Чыршылы торак пунктында Заречная урамы, Үзәк урамы, Урман урамы буенча юлларны кардан чистарту

«РИЗА» «КАРШЫ» соравы буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 317 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 160.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 160 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Яңа Чыршылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Яңа Чыршылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Яңа Чыршылы авыл җирлеге Яңа Чыршылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

Җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү,

Яңа чыршылы бистәсе территориясендә үлән чабу,

Үзәк урамындагы иске агачларны кисү;

торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Яңа Чыршылы торак пунктында Лесная урамы буенча туфрак- вак таш җәелгән юлларны ремонтлау,

-Яңа Чыршылы торак пунктында чокыр ремонтлау (асфальт)

- Яңа Чыршылы торак пунктында Заречная урамы, Үзәк урамы, Урман урамы буенча юлларны кардан чистарту соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Яңа Чыршылы поселогы, Заречная, 25 йорт, Центральная, 12А йорты адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә.Мөхәмәтшина